ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗЕЛЕНОДОЛЬСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
**26.01.2018**

Зеленодольск шәһәре

**КАРАР**
**№ 151**

Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2014 елның 31 июлендәге «Зеленодольск муниципаль районының авария хәлендәге күп фатирлы йортлары исемлеген раслау турында» 1553 номерлы карарына, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2011 елның 31 декабрендәге «Зеленодольск муниципаль районының күп фатирлы йортларын авария хәлендә һәм сүтелергә тиешле дип тану турында» 2425 номерлы карарына үзгәрешләр кертү, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2015 елның 3 декабрендәге «Зеленодольск шәһәре, Татарстан урамы, 15/а йорт адресы буенча һәм анда урнашкан күчемсез мөлкәт объектларын тартып алу турында» 2649 номерлы һәм «Зеленодольск шәһәре, Татарстан урамы, 15/а йорт һәм анда урнашкан күчемсез мөлкәт объектларын тартып алу турында» 2016 елның 16 августындагы 2166 номерлы карарлары үз көчләрен югалткан дип тану турында

Зеленодольск шәһәр судының 2017 елның 23 декабрендәге 2-2326/2017 номерлы карарын үтәү йөзеннән, Зеленодольск муниципаль районының Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2014 елның 31 июлендәге «Зеленодольск муниципаль районының авария хәлендәге күп фатирлы йортлары исемлеген раслау турында» 1553 номерлы карары кушымтасына үзгәрешләр кертергә, «Зеленодольск шәһәре, Татарстан урамы, 15а йорты» 259 пунктын төшереп калдырырга.
2. Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2011 елның 31 декабрендәге«Зеленодольск муниципаль районының күп фатирлы йортларын авария хәлендә һәм сүтелергә тиешле дип тану турында»

2425 номерлы карарының кушымтасына үзгәрешләр кертергә, «Зеленодольск шәһәре, Татарстан урамы, 15а йорты» 107 пунктын төшереп калдырырга.

3. Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2015 елның 3 декабрендәге «Зеленодольск шәһәре, Татарстан урамы, 15/а йорт адресы буенча һәм анда урнашкан күчемсез мөлкәт объектларын тартып алу турында» 2649 номерлы һәм «Зеленодольск шәһәре, Татарстан урамы, 15/а йорт һәм анда урнашкан күчемсез мөлкәт объектларын тартып алу турында» 2016 елның 16 августындагы 2166 номерлы карарлары үз көчләрен югалткан дип танырга.

4. Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары О.А. Матвеевага әлеге карарның күчермәсен түбәндәгеләргә җибәрергә:

- күчемсез мөлкәткә хокукларны һәм аның белән алыш-бирешләрне дәүләт теркәвенә алучы органга;

- «Зеленодольск муниципаль районының торак сәясәте департаменты » МКУ;

- торак урыннар милекчеләренә.

5. ЗМР Советы аппаратының җәмәгатьчелек, массакүләм мәгълүмат чаралары белән элемтә бүлеге начальнигына Д.С. Анисимовка әлеге карарны «Зеленодольская правда» газетасында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Зеленодольск муниципаль районының мәгълүмат сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) урнаштыруны тәкъдим итәргә.

6. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең авария хәлендәге торактан гражданнарны күчерү программасын гамәлгә ашыру буенча урынбасары О.А.Матвеевага йөкләргә.

Җитәкче А.Х.Сәхибуллин